МИНИСТЕРСТВО ТРАНСПОРТА
И ДОРОЖНОГО ХОЗЯЙСТВА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТРАНСПОРТ ҺӘМ ЮЛ
ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

**БОЕРЫК** **ПРИКАЗ**

12.11.2019 № 590

Казан ш.

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының 2018 елның 19 декабрендәге 634 номерлы боерыгы белән расланган региональ һәм муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышын тәэмин итү буенча региональ дәүләт күзәтчелеген башкаруның Административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының 2018 елның 19 декабрендәге 634 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының 2019 елның 29 апрелендәге 190 номерлы боерыгы белән кертелгән үзгәреш белән) белән расланган региональ һәм муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышын тәэмин итү буенча региональ дәүләт күзәтчелеген башкаруның Административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.14 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясы нигезендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына карата, алар турында белешмәләр кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрына кертелгәндә, планлы тикшерүләр 294-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән таләпләр нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

2.16 пунктының икенче һәм өченче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«югары риск категориясе өчен - ике елга бер тапкыр;

урта риск категориясе өчен - дүрт елга бер тапкырдан да ешрак түгел һәм биш елга бер тапкырдан да ким түгел;»;

2.17 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.17. Планлы тикшерүне еллык планга кертү өчен нигез булып, әлеге Регламентның 2.16 пунктында күрсәтелгән чорны планлы тикшерүне уздыру елында тәмамлау тора:

1) юридик затны, индивидуаль эшкуарны соңгы планлы тикшерүне үткәрүне тәмамлау;

2) юридик затны яисә индивидуаль эшкуарны дәүләт теркәвенә ала башлау, тиешле эшчәнлек өлкәсендә вәкаләтле вәкилгә тапшырылган дәүләт контроле (күзәтчелеге) органы тарафыннан эшләр башкарылган яки күрсәтелгән хәбәрнамәне бирүне таләп иткән очракта, әгәр планлы тикшерүләр элегрәк үткәрелмәгән булса, яисә Россия Федерациясе законнарында каралган башка гамәлләр яисә вакыйгалар булса, эшкуарлык эшчәнлегенең аерым төрләрен гамәлгә ашыра башлау турында хәбәрнамә нигезендә эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлау турында хәбәрнамә.».

Министр вазыйфаларын башкаручы А.Н. Усманов